Республика Татарстан
**СОВЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ахмадиева, д.26, п. Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail:POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК СОВЕТЫ**

Ахмадиевурамы, 26 йорт, Җәлил поселогы,423368
Телефон: (85559) 31-0-97,60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

**РЕШЕНИЕ**
14.06.2024 ел

**КАРАР**
№189

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәте өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 04 июнендәге 92 номерлы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге карары нигезендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының, Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына, Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Уставына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында"

1. Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәте өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 04 июнендәге 92 номерлы карарына (Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 2018 елның 10 июлендәге 98 номерлы, 2018 елның 26 октябрендәге 109 номерлы, 05.02.2021 елның 28 номерлы, 03.10.2022 елның 100, 10.01.2023 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 3 пунктындагы 1 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затына айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә чыгымнар күләме елына 17,40 айлык акчалата бүләкләү тәшкил итә.».

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Штат расписаниесен расларга.

4. Әлеге карар 2024 елның 01 июленнән үз көченә керә.

5. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә әлеге карарны урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының бюджеты һәм икътисадый мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе

Р. Ә. Кәримов